# ГӨЛФИЯ

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Яз җиткәч, кошлар кайталар,
Сагынып туган якларын.
Сайрый-сайрый уяталар
Мәхәббәт чаткыларын.

Язгы кичләрнең берсендә
Тәрәз төбеңә килдем.
Гармунымны кулга алып,
Исемеңне көйгә салып,
Шушы жырны җырладым:

**Кушымта:**

Гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-Гөлфиянең
Бигрәк матур тавышы!
Гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-Гөлфиянең
Сызылып тора кашы!

Гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-Гөлфиянең
Шаян икән күзләре!
Гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-Гөлфия, җанкаем!
Рәхәт үтсен көннәрең!

2. Язлар үтте, үтте җәйләр,
Менә көзләр дә җитте.
Көньякка киткән кошлардай
Яшь вакыт үтеп китте.

Тик һаман яши күңелдә
Тәүге сөю хисләрем,
Гармунымны кулга алып,
Исемеңне көйгә салып,
Сиңа әйткән сүзләрем:

**Кушымта.**

**Гульфия**

Посвящается девушкам по имени Гульфия.

Помнишь, Гульфия, как брал я в руки гармонь, играл под твоими окнами и пел для тебя? Эх, вернуть бы те деньки золотые!..